**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 18.03.2022** **№ 331**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында «Торак-2022» янгын-профилактик операциясен үткәрү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Тәкъдим итәргә:

1.1 Район авыл җирлекләре башлыкларына:

- торак пунктларның торак фондында янгын-профилактика эшләрен үткәрүне күздә тоткан тиешле норматив-хокукый актлар кабул итәргә;
- олы яшьтәге ялгыз гражданнарның, социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрнең, имин булмаган һәм күп балалы гаиләләрнең яшәү урынын исәпкә һәм контрольгә алырга;
-янгын сүндерү-профилактика эшен уздыруны, яшәү урыны буенча гражданнарны көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне, халык арасында агитация һәм пропаганда материаллары әзерләүне һәм таратуны, аз керемле гражданнарга мич җылытуын һәм электр үткәргечләрен ремонтлау буенча социаль ярдәм күрсәтүне, шулай ук башка янгын-профилактика чараларын үткәрүне оештырырга;
- авыл торак пунктларында янгынга каршы инструктаж уздыруга старосталарны җәлеп итүне тәэмин итәргә;
-шәхси йортларда (фатирларда) янгын турында автоном хәбәр бирә торган җайланмаларны үз акчалары исәбенә урнаштыру зарурлыгы турында халык арасында агитация эше алып барырга, ялгыз өлкән гражданнар, инвалидлар һәм халыкның социаль яктан имин булмаган катламнары яшәү урыннары өчен түләүсез урнаштыру мөмкинлекләрен эзләргә.

1.2 Биектау районы буенча Россия ЭЭМ бүлегенә (Вәлиев А.З.):

-«Торак - 2022» янгын-профилактик операциясендә Биектау районы буенча Эчке эшләр министрлыгы бүлегенең участок вәкаләтле полиция хезмәткәрләре катнашуын тәэмин итәргә һәм хезмәт күрсәтелә торган территорияләрдә янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау һәм агитацияләү эшен активлаштырырга;

- социаль җайлаштырылмаган гражданнарның, спиртлы эчемлекләр һәм наркотик матдәләрне күп кулланучы затларның, имин булмаган күпбалалы гаиләләрнең һәм билгеле бер яшәү урыны булмаган затларның яшәү урыннарының янгын куркынычсызлыгы торышын тикшерүне оештырырга;

-социаль җайлаштырылмаган гражданнарның, спиртлы эчемлекләр һәм наркотик матдәләр кулланучы затларның, имин булмаган күпбалалы гаиләләрнең һәм билгеле бер яшәү урыны булмаган затларның яшәү урыннары турында яңартылган белешмәләрне (исемлекләрне) квартал саен Биектау муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлегенә тапшыруны оештырырга.

1.3 Биектау янгын сүндерү-коткару гарнизонына (Шәймәрдәнов Р.Р.):

- торак пунктларда янгын сүндерү-коткару частенең шәхси составын янгын сүндерү-профилактика эшен уздыру өчен тупларга;

- профилактик төркемнәр составында ГПС хезмәткәрләренең (эшчәннәренең) эшен исәпкә алу журналын кертергә;

- торак пунктларны янгын сүндерү-коткару частенең шәхси составына йорт саен йөрү өчен беркетергә;

- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм районның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе утырышында Биектау муниципаль районын янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының торышы мәсьәләсен карау турында тәкъдимнәр кертергә.

1.4 Биектау муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлегенә (Разгулов А.М.):

- янгын сүндерү-коткару частенең шәхси составы һәм торак фондын профилактик карауда катнашучы затлар белән дәресләр оештырырга һәм уздырырга;

- районның тиешле хезмәтләре ярдәмендә күп балалы гаиләләрнең, патронаж исәбендә торучы социаль куркыныч хәлдәге балалары булган гаиләләрнең яшәү урыннары исемлекләренә корректировка кертеп торырга.

1.5 Биектау муниципаль районындагы МТЗ һәм СЗ социаль яклау идарәсенә (Минаева Г.Р.):

- олы яшьтәге ялгыз гражданнарга һәм күп балалы гаиләләргә хезмәт күрсәтүче социаль хезмәткәрләрне янгын куркынычсызлыгы чараларын һәм көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүне пропагандалауда белешмәлекләр таратуга җәлеп итәргә.

- Биектау муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлегенә квартал саен патронаж исәбендә торучы, социаль куркыныч хәлдәге күпбалалы гаиләләрнең, балалы гаиләләрнең, ялгыз яшәүче гражданнарның, өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның яшәү урыннарының яңартылган белешмәләрен (исемлекләрен) тапшыруны оештырырга.

1.6 Биектау РЭГСына (Шәймуллин Р.З.):

-газ хезмәте хезмәткәрләре газ приборларының торышын тикшергәндә, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре таләпләрен үтәүгә игътибар бирергә һәм торак фондында янгыннарны профилактикалау буенча пропаганда һәм агитация эше үткәрергә;

- кварталга кимендә бер тапкыр счет-фактура битләренең кире ягында янгын куркынычсызлыгы чаралары буенча белешмәлекләр урнаштыруны күздә тотарга.

1.7 Биектау РЭГСына (Гыйниятуллин М.Н.):

-Биектау РЭСы хезмәткәрләре тарафыннан электр хуҗалыгы торышын тикшергәндә, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре таләпләрен үтәүгә игътибар бирергә һәм торак фондында янгыннарны профилактикалау буенча пропаганда һәм агитация эше үткәрергә кирә.

1.8 «Татэнергосбыт» АҖ Идел буе бүлегенә (Саләхетдинов А.Г.):

- кварталга кимендә бер тапкыр счет-фактура битләренең кире ягында янгын куркынычсызлыгы чаралары буенча белешмәлекләр урнаштыруны күздә тотарга.

1.9 Идарәче компанияләргә, торак милекчеләре ширкәтләренә:

- гражданнарны аларның яшәү урыны буенча көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чараларына, фатирларда яшәүчеләргә белешмә тарату юлы белән өйрәтүне оештырырга;

- кварталга кимендә бер тапкыр счет-фактура битләренең кире ягында янгын куркынычсызлыгы чаралары буенча белешмәлекләр урнаштыруны күздә тотарга;

-саклау объектларын капиталь ремонтлауны, реконструкцияләүне яисә техник яктан яңадан коралландыруны үткәргәндә торак биналар (бүлмәләр), алгы бүлмәләр (алар булган очракта) һәм фатирлар коридорларын, бинаның катлылыгына бәйсез рәвештә, шул исәптән бер фатирлы һәм блокланган торак йортларны автоном төтенле янгын турында хәбәр бирүче җайланмалар белән җиһазландырырга.

1.10 Биектау муниципаль районының милекнең барлык рәвешләрендәге предприятиеләр һәм оешмаларына:

- үз хезмәткәрләре арасында көнкүрештә һәм эш урыннарында янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү буенча агитация алып бару эшен оештырырга.

1.11 «Татмедиа» АҖ филиалы «Биектау хәбәрләре» газетасы редакциясенә» (Мостафина Э.А.):

- массакүләм мәгълүмат чараларында торак пунктларның торак фонды янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә үткәрелә торган чараларны һәм проблемалы мәсьәләләрне яктыртуны оештырырга.

2. Янгыннарны профилактикалау буенча профилактик төркемнәр исемлеген расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Хисамутдинов